Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

2020 елның 5 июне 312№

Әлки муниципаль районында муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Әлки муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тәкъдим итү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 8 статьясын, 2014 елның 22 декабрендәге 431-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон редакциясендә, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 23 мартындагы УП-308 номерлы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында»гы Әмере, Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясын тормышка ашыру максатларында һәм коррупциягә каршы тору эшчәнлеген камилләштерү максатларында Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 92 номерлы карары (2015 елның 18 декабрендәге 22 номерлы редакциясендә) белән расланган Әлки муниципаль районында муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Әлки муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тәкъдим итү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта «ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга, Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы: А. Ф. Никошин